КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 март г.Казань № 151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы һәм 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (02.04.01 <*>);

норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03 <*>);»;

3.3 нче пунктта:

3.3.17 нче пунктча үз көчен югалткан дип санарга;

3.3.82 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.82. Газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләрен раслау, үзгәртү, бетерү һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр кертү, аларны бетерү (өстәмә йөкләмәләр билгеләү) турында карарлар кабул итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.102 нче пунктча өстәргә:

«3.3.102. Дәүләт милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутларны билгеләмичә, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектлар урнаштыруга рөхсәтнамә бирә.»;

4.1.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5. Җирле үзидарә органнары белән муниципаль милектәге мөлкәт һәм җир кишәрлекләре, шулай ук алар белән эш итү вәкаләтләре Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә тапшырылган җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзергә. Әлеге мөлкәт һәм җир кишәрлекләре белән эш итү буенча карарлар проектларын һәм алар белән алыш-бирешләр ясауны мониторинглау һәм килешүләрне тормышка ашыруны анализлауны гамәлгә ашырырга.

Җир кишәрлекләрен кулланудан алу һәм бирү мәсьәләләре, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләренә бәйле башка мәсьәләләр буенча законсыз карарларны гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимнәрне җирле үзидарә органнарына кертергә.»;

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгы турындагы
нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 14 март, 151 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
предприятиеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итә торган
икътисадый эшчәнлек төрләре
ИСЕМЛЕГЕ

| Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) <*> | Икътисадый эшчәнлек төрләре исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 68 | Күчемсез мөлкәт белән операцияләр |
| 68.1 | Шәхси күчемсез мөлкәтне сатып алу һәм сату |
| 68.10 | Шәхси күчемсез мөлкәтне сатып алу һәм сату |
| 68.10.1 | Шәхси күчемсез мөлкәтне сатуга әзерләү |
| 68.10.11 | Шәхси торак күчемсез мөлкәтне сатуга әзерләү |
| 68.10.12 | Шәхси торак булмаган күчемсез мөлкәтне сатуга әзерләү |
| 68.10.2 | Шәхси күчемсез мөлкәтне сатып алу һәм сату |
| 68.10.21 | Шәхси торак күчемсез мөлкәтне сатып алу һәм сату |
| 68.10.22 | Шәхси торак булмаган биналарны һәм урыннарны сатып алу һәм сату |
| 68.10.23 | Җир кишәрлекләрен сатып алу һәм сату |
| 68.2 | Шәхси яки арендага алынган күчемсез мөлкәтне арендалау һәм алар белән идарә итү |
| 68.20 | Шәхси яки арендага алынган күчемсез мөлкәтне арендалау һәм алар белән идарә итү |
| 68.20.1 | Шәхси яки арендага алынган торак күчемсез мөлкәтне арендалау һәм алар белән идарә итү |
| 68.20.2 | Шәхси яки арендага алынган торак булмаган күчемсез мөлкәтне арендалау һәм алар белән идарә итү |
| 68.3 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә күчемсез мөлкәт белән операцияләр |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 68.31 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә күчемсез мөлкәт агентлыклары эшчәнлеге |
| 68.31.1 | Күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.11 | Торак күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.12 | Торак булмаган күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.2 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә күчемсез мөлкәтне арендалау буенча арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.21 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә торак күчемсез мөлкәтне арендалау буенча арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.22 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә торак булмаган күчемсез мөлкәтне арендалау буенча арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.3 | Күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.31 | Торак күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.32 | Торак булмаган күчемсез мөлкәтне сатканда-сатып алганда бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.4 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә күчемсез мөлкәтне арендалау буенча консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.41 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә торак күчемсез мөлкәтне арендалау буенча консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.42 | Бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә торак булмаган күчемсез мөлкәтне арендалау буенча консультация хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.5 | Күчемсез мөлкәтне бәяләгәндә бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.51 | Торак күчемсез мөлкәтне бәяләгәндә бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 68.31.52 | Торак булмаган күчемсез мөлкәтне бәяләгәндә бүләкләүгә яки шартнамә нигезендә арадашчы хезмәтләре күрсәтү |
| 69.20.1 | Финанс аудиты үткәрү эшчәнлеге |
| 71.12.7 | Кадастр эшчәнлеге |
| 71.12.46 | Җир төзелеше |
| 74.90.22 | Зат мөлкәтен, шул исәптән билгеле бер төрнең (күчемле яки күчемсез, шул исәптән предприятие) мөлкәтен тәшкил иткән әйберләр җыелмасының базар яки башка кыйммәтен билгеләүгә юнәлдерелгән эшчәнлек |
| 77.33 | Офис машиналарын һәм җиһазларны (хисаплау техникасын да кертеп) арендалау һәм лизинглау |
| 77.33.1 | Офис машиналарын һәм җиһазларны арендалау һәм лизинглау |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 77.33.2 | Хисаплау машиналарын һәм җиһазларны арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.2 | Бүтән төркемнәргә кертелмәгән башка машиналарны һәм җиһазларны арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.21 | Двигательләрне, турбиналарны һәм станокларны арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.23 | Күтәрткеч транспорт җайланмасын арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.24 | Һөнәри радио һәм телевидение аппаратурасын һәм элемтә аппаратурасын арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.25 | Тикшерү-үлчәү аппаратурасын арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.26 | Медицина максатларында кулланыла торган әсбапларны, аппаратларны һәм башка җиһазларны арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.27 | Сәүдә җиһазын арендалау һәм лизинглау |
| 77.39.29 | Фәнни һәм сәнәгати билгеләнештәге җиһазларны һәм башка машиналарны арендалау һәм лизинглау |
| 84.11.4 | Салым салу өлкәсендәге эшчәнлек һәм финанс эшчәнлеге белән идарә итү |
| 84.11.8 | Дәүләт милкендәге мөлкәт белән идарә итү |

<*> Икътисадый эшчәнлек төрләре кодларын билгеләү Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст номерлы боерыгы белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы. 029-2014 гомумроссия классификаторы (КДЕС 2 нче ред.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

___